ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.05.2023 Юеш Көрнәле ав. № 11

**Хайваннарны хуҗаларсыз кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2019 № 1275 « Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» карары нигезендә, Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге чикләрендә хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе хайваннарны хуҗаларсыз элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат булып тора.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе** **И.Л.Хушанова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Бутлеровка авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
«13» май 2023 ел, № 11
карарына кушымта

Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге чикләрендә хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Элеккеге яшәү урыннарына кайтару тыела (башка хайваннарга яки кешегә карата мотивациясез агрессивлык күрсәтмәгән хуҗаларсыз хайваннарны тоту урыны, хайваннар өчен приютта мондый хайваннарны приютта, тоту мөмкинлеге булмаган очракта стерильләштерү, билгеләү, исәпкә алу, карантин, дәвалау, вакцинация чаралары тәмамланганнан соң территорияләрдә һәм 500 метр ераклыктагы территорияләрдә:

-социаль өлкә учреждениеләре;

-сәламәтлек саклау объектлары;

- мәгариф учреждениеләре (мәктәпләр, балалар бакчалары);

-мәдәният объектлары;

-балалар уен һәм спорт мәйданчыклары;

- җәмәгать территорияләре (бакчалар, парклар, скверлар ,урамнар, торак пунктлар мәйданнары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары);

-массакүләм чаралар үткәрү өчен мәйданчыклар;

-стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары, сәүдә нокталары территорияләре;

-зиратлар һәм мемориаль зоналар.